| | |
|---|---|
| Республика Татарстан | Татарстан Республикасы |
| Менделеевский муниципальный район | Менделевск муниципаль районы |
| Исполнительный комитет | Турай авыл җирлеге |
| Тураевского сельского поселения | башкарма комитеты |

**Постановление** **Карар**

**№26** **2020 елның 16 июленнән**

Нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына үзгәрешләр кертү турында:
васыятьнамә таныклыгы яки ышанычнамә таныклыгы

"Дәүләт муниципаль хезмәтләре күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:
1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 21 февралендәге 10 номерлы карары белән расланган Нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты: васыятьнамә таныклыгы яки ышанычнамә таныклыгына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Административ регламентның 2.9 пунктының 2 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Документлар кабул итүдән баш тарту нигезләре:
мондый гамәлне башкару Россия Федерациясе законнарына каршы килә;
гамәл башка җирлек, муниципаль, шәһәр округы яисә муниципаль район җирле үзидарәсенең вазыйфаи заты (мирас мөлкәтен саклау буенча чаралар кабул итүгә карата) яисә нотариус тарафыннан башкарылырга тиеш;
нотариаль гамәл кылу турында үтенеч белән эшкә сәләтсез граждан йә кирәкле вәкаләтләре булмаган вәкил, яшәү урыны буенча яки тору урыны буенча теркәлмәгән граждан мөрәҗәгать итсә;
ышанычнамә Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килми;
нотариаль гамәлләр башкару өчен тапшырылган документлар Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килми;
нотариаль гамәл кылу өчен тапшырылган документларда бәян ителгән фактлар, раслау Россия Федерациясе законнары нигезендә таләп ителгән очракта, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланмаган.»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Турай авыл җирлеге» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Турай авыл җирлеге
Башлыгы А.М.Рәхимова